ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.10.2022 г. Заинск № 506

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү, мондый категориядәге гражданнарның социаль якланганлык дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар күрү максатында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм алу тәртибе» 2 нче кушымтасының Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве күләмен исәпләү, билгеләү һәм үзгәртү тәртибе» 2 кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен исәпләү, билгеләү һәм үзгәртү тәртибенең II өлеше дүртенче абзацында "полиция хезмәткәрләренең балалары өчен" сүзләрен «Россия Эчке эшләр министрлыгының Зәй районы буенча бүлеге хезмәткәрләренең балалары өчен» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен исәпләү, билгеләү һәм үзгәртү тәртибенең II өлеше бишенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Хәрби хезмәт үтүче һәм махсус хәрби операциядә катнашучы мобилизацияләнгән гражданнарның балалары өчен ата-аналар түләве алынмый (Татарстан Республикасы Зәй шәһәре һәм Зәй районы Хәрби комиссариаты тарафыннан бирелгән исемлекләр нигезендә)».

2. Әлеге карар, 2022 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган 1.2 пунктчадан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42